БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 декабря 2021 ел № 94

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2016 елның 28 апрелендә 37 номеры белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 44 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

**1.** Түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1) Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«5) Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, Район чикләрендә пунктлар чикләреннән читтә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»;

**2) Уставның 6 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктын өстәргә:**

«9.1) Район чикләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләреннән читтә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;»; (2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)

**3) 6 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 41 пунктча өстәргә:**

«41) муниципаль районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.»;

**4) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пунктны өстәргә:**

«3. Әлеге Уставның 6 һәм 8 статьяларында каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

кысаларында муниципаль контроль төре Район чикләрендә тиешле төр контроль объектлары булганда гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

**5) Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 28 пунктчасында** "файдалану һәм саклау" сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

**6) Уставның 7 статьясындагы 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 15 пунктчаны өстәргә:

«15) алкогольле, наркотик яки башка агулы(токсинлы) исереклек хәлендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;»;

**7) Уставның 7 статьясындагы 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 16 пунктчаны өстәргә:

«16) муниципаль янгын сагы булдыру.»; (2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)

**8) Уставның 8 статьясына түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктны өстәргә:**

1.1) бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

**9) Уставның 8 статьясына түбәндәге эчтәлекле 1 пунктны өстәргә:**

«1) Район составына керүче җирлекләр (алга таба - авыл җирлекләре) чикләрендә электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;»;

**10) Уставның 8 статьясындагы 2пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«2) парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итүне дә кертеп, авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»;

**11) Уставның 8 статьясындагы 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«11) авыл җирлекләренең урманнарыннан, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләре урманнарыннан файдалануны, аларны саклауны, яклауны, яңадан торгызуны оештыру;»;

**12) Уставның 8 статьясындагы 12 пунктта** «Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән бинаны сүтү турында карар, рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешенең, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән иң чик параметрларына туры китерү (алга

таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү) турында карар кабул итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

**13) Уставның 8 статьясындагы 16 пунктта** «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

**14) Уставның 8 статьясындагы 24 пунктта** «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» сүзләренә алмаштырырга;

**15) Уставның 8 статьясына түбәндәге эчтәлекле 25 пунктны өстәргә:**

«25) карарлар кабул итү һәм авыл җирлекләре территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларына хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар үткәрү, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез милек объектларының хокукка ияләре турында мәгълүматлар җибәрү.»;

**16) Уставның 13 статьясындагы 4 пунктка** «җәмәгать фикер алышулары» сүзләрен өстәргә;

**17) Уставның 13 статьясына** түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктны өстәргә:

«8.1) инициатив проектлар;

**18) Уставның 16.1 статьясындагы** 8 пунктта «3 пунктта» сүзләрен «7 өлешнең 5 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

**19) Уставның 16.1 статьясындагы** 9 пунктта «(район Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены)» сүзләрен төшереп калдырырга;

**20) Уставның 16.1 статьясындагы** 10 пунктта «3 пунктта» сүзләрен «3, 6, 7, 8, 9, 11 12 өлешләр» сүзләренә алмаштырырга;

**21) Уставның 17 статьясындагы 12 пунктында**сүзләр «Расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары буенча» сүзләрен «Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

**22) Уставның 26 статьясындагы 1 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район Советы депутаты вәкаләтләре җирлек башлыгы вазыйфасына кергәннән яки җирлек Советы депутатын район Советы депутаты итеп сайланганнан көннән башлана һәм яңа сайланган җирлек башлыгы вазыйфасына кергән көннән яки әлеге җирлектән депутатны Район Советы составына сайлау турында карар үз көченә кергән көннән туктатыла.»;

**23) Уставның 26 статьясындагы 7 пунктның 7 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган чит ил дәүләте - Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы гражданлыгы бетү, чит ил дәүләте гражданлыгы (буйсынуда булу) яисә яшәүгә рөхсәт яки Россия Федерациясе гражданының яисә әгәр Россия

Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»

**24) Уставның 26 статьясындагы 8 пунктында** «үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы» сүзләрен төшереп калдырырга;

**25) Уставның 40 статьясындагы 3 пунктка** түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлешне өстәргә:

«3.1. Район Башлыгы Урынбасары тарафыннан Район Башлыгы вәкаләтләрен башкару мөмкин булмаган очракта яисә аның булмавына бәйле рәвештә Район Башлыгы вәкаләтләрен үтәү Район Советы депутатына йөкләнә.

Вәкаләтләр Район Башлыгы күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә.

Район Башлыгы тарафыннан тиешле күрсәтмәне чыгару мөмкин булмаган очракта, Район Башлыгы вазыйфаларын башкаручыны билгеләү Район Советы карары белән гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрне йөкләү турында карар Район Советының чираттан тыш утырышында утырышта катнашкан район Советы депутатлары саныннан күпчелеге белән кабул ителә.»;

**26) Уставның 43 статьясындагы 1 пунктның 3 пунктчасында алтынчы абзацта:** «файдалану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

**27) Уставның 43 статьясындагы 1 пунктның 3 пунктчасындагы тугызынчы абзац** үз көчен югалткан дип танырга;

**28) Уставның 43 статьясындагы 1 пунктның 4 пунктчасында икенче абзацны**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итә, Район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, юл хәрәкәтен оештыруны гамәлгә ашыра һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;»

**29) Уставның 43 статьясындагы 1 пунктның 7 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле ундүртенче абзацны өстәргә:

« - район чикләрендә шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләреннән читтә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүне гамәлгә ашыра» (2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)

**30) Уставның 43 статьясындагы 2 пунктның беренче абзацында** «Җирлекнең» сүзен «Районның» сүзенә алмаштырырга»;

**31) Уставның 43 статьясындагы 2 пунктның** 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы федераль

законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;»;

**32) Уставның 43 статьясындагы 2 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 13-15 пунктчаларын өстәргә:

«13) инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен физик культура һәм спорт, адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә ярдәм күрсәтү;

14) алкогольле, наркотик яки башка агулы (токсинлы) исереклек хәлендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;

15) муниципаль янгын сагын булдыру.»; (2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)

**33) Уставның 43 статьясындагы 3 пунктын**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Район башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль өлкәсендә Район башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге Район Советы билгеләгән тәртиптә алып барыла;

2) аны гамәлгә ашыру вәкаләтләре җирле үзидарә органнарына бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан раслана торган типлаштырылган административ регламентлар нигезендә гамәлгә ашыру вәкаләтләре җирле үзидарә органнарына бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә аны уздыру күрсәткечләре һәм методикасы, авыл җирлекләрендә җирле үзидарә вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрольдән тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны оештыру һәм үткәрү;

5) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә Район Башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә

карата «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезләмәләре кулланыла.»;

**34) Уставның 45 статьясындагы 3 пунктны**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатларда түбәндәгеләр булырга тиеш:

- «дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча югары белем яисә Район Советы карары белән билгеләнә торган башка белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча югары белем;

- ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки дүрт елдан да ким булмаган белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы;

- оешма, дәүләт органы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында биш елдан да ким булмаган идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе;

- Район Советы карары белән билгеләнә торган Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле күләмдә эшлекле сыйфатлар һәм күнекмәләр.»;

**35) Уставның 45 статьясындагы 9 пунктының икенче абзацын төшереп калдырырга;**

**36) Уставның 45 статьясындагы 9.1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 4 пунктны өстәргә:

«4) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган чит ил дәүләте - Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы гражданлыгы бетү, яисә чит ил дәүләте гражданлыгы (буйсынуда булу) алу яисә яшәүгә рөхсәт яки Россия Федерациясе гражданының яисә әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу турында бу хакта аңа билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит дәүләте гражданлыгы туктатылганнан яисә чит ил дәүләте гражданлыгын (буйсынуда булу) алганнан, яисә яшәүгә рөхсәт яки әлеге пункт белән каралган башка документны алганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Район Башлыгына язмача хәбәр итәргә бурычлы.»;

**37) Уставның 46 статьясындагы 1 пунктында** «ике елга» сүзеннән соң «һәм биш елдан да артык түгел» сүзләрен өстәргә;

**38) Уставның 48 статьясындагы 1 пунктының 9 пунктчасын**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган чит ил

дәүләте - Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы гражданлыгы бетү, чит ил дәүләте гражданлыгы (буйсынуда булу) яисә яшәүгә рөхсәт булу яки Россия Федерациясе гражданының яисә әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

**39) Уставның 48 статьясындагы 1 пунктының 11 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3, 3.1-1, 3.2, 3.3, 4 - 6.2, 7 - 7.2 өлешләре нигезендә Районны үзгәртеп корулар, шулай ук Район бетерелгән очракта;»;

**40) Уставның 56 статьясындагы 1 пунктны**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - җирле үзидарә органы, Район сайлау комиссиясе яисә муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча бурычлар даирәсе белән әлеге Устав нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органында, Район сайлау комиссиясе аппаратында вазыйфа.»;

**41) Уставның 57 статьясын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«57 статья. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, муниципаль хезмәткәр

1. Муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат булып депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган, комиссиядә даими (штат) нигезендә эшләүче хәлиткеч тавыш бирү хокукы булган сайлау комиссиясе әгъзасы, шул исәптән Районның Контроль-хисап палатасы рәисе тора.

2. Муниципаль хезмәткәр булып Район бюджеты акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата хезмәт хакына (содержаниега) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча бурычларны башкаручы граждан тора.

2. Районның җирле үзидарә органнары, сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча бурычларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләми һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.»;

**42) Уставның 58 статьясындагы 9 пунктының 3 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә торырга хокуклы булган чит ил дәүләте - Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы гражданлыгы бетү турында бу хакта муниципаль хезмәткәргә билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә торырга хокуклы булган чит ил дәүләте - Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы гражданлыгы (буйсынуда булу) беткәннән соң, әмма биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә бурычлы;»;

**43) Уставның 58 статьясындагы 3 пунктының 9 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:

«9.1) чит ил дәүләте гражданлыгы (буйсынуда булу) алу яисә яшәүгә рөхсәт яки Россия Федерациясе гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу турында бу хакта муниципаль хезмәткәргә билгеле булган көнне, әмма чит ил дәүләте гражданлыгын (буйсынуда булу) алганнан яисә яшәүгә рөхсәт яки гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документны алганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә бурычлы;»;

**44) Уставның 74 статьясын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«74 статья. Муниципаль хокукый актлар әзерләү.**

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары аларны алып бару мәсьәләләре буенча Район Башлыгы, Район Советы депутатлары, Район Башкарма комитеты җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, шулай ук Районның Контроль-хисап палатасы, Районның финанс-бюджет палатасы, Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан кертелә ала.

Балтач муниципаль районы прокуроры, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү кирәклеген билгеләгәндә, муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, гамәлдән чыгару яки кабул итү турында проектлар һәм тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

2. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе, аларга беркетеп бирелә торган документларның исемлеге һәм формасы Район Советы регламенты, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

3. Эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләрнең, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларның яңаларын билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралганнарны үзгәртә торган, әлеге статьяның 6 өлеше нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы законы белән тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларының әлеге статьяның 6 өлеше нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Законы белән тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бәяләнергә тиеш, түбәндәгеләрдән тыш:

1) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгели, үзгәртә, туктатып тора, гамәлдән чыгара торган Район Советы норматив хокукый актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Район Советының норматив хокукый актлары проектлары;

3) Гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәргеч бирә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә.

5. Татарстан Республикасы законы белән эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләрнең, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычларның яңаларын билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралганнарны үзгәртә торган норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру мәҗбүри булган муниципаль районнар исемлеге билгеләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы законы белән, мондый муниципаль берәмлекләргә йөкләнгән дәүләт вәкаләтләренең концентрациясе дәрәҗәсен дә кертеп, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне гамәлгә ашыруның объектив үзенчәлекләрен чагылдыра торган, муниципаль районнарны күрсәтелгән исемлеккә кертү критерийлары билгеләнә.».

**45) Уставның 78 статьясына** түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1. Норматив-хокукый актларны рәсми бастырып чыгаруның өстәмә чыганагы булып Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» хокукый порталы (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф) тора.».

**46) Уставның 84 статьясындагы 7 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Җыелышына хатындагы Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләрен) билгели торган нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар

Россия Федерациясенең Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).».

**47) Уставның 84 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацына** «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясында каралган очракларда» сүзләрен өстәргә;

**48) Уставның 84 статьясындагы 10 пунктының өченче абзацына** «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясында каралган очракларда» сүзләрен өстәргә»;

**49) Уставның 86.1 статьясындагы 1 пунктында**«15.1 статьясы белән» сүзләрен «16.1 статьясы белән» сүзләренә алмаштырырга;

**50) Уставның 86.1 статьясындагы 3 пунктының 2 абзацында** «(Район Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены карары белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

**51) Уставның 87 статьясындагы 2 пунктны** төшереп калдырырга;

**52) Уставның 88 статьясындагы 3 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Район бюджеты үтәлешенә казначылык хезмәте күрсәтү, Район бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счетларын, Район бюджетының бердәм счетын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

**53) Уставның 89 статьясындагы 4 пунктында** «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

**54) Уставның 89 статьясындагы 5 пунктны**түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап, аны район Советында карап тикшергәнче, бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне һәм Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә алган тышкы тикшерү узарга тиеш.

Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Район Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә, Район Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла. Район составына керүче шәһәр, авыл җирлеге Советы мөрәҗәгате буенча шәһәр, авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү Районның Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарылырга мөмкин.»;

**55) Уставның 89 статьясындагы 6 пунктында** «баш идарәчеләр» сүзләрен «баш администраторлар» сүзләренә алмаштырырга;

**56) Уставның 89 статьясындагы 7 пунктында** «кушымта белән» сүзләреннән соң «бюджет һәм бюджет хисаплылыгын үтәүгә анализны үз эченә алган аңлатма язуы һәм муниципаль йөкләмәне үтәү һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләрен файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

**57) Уставның 89 статьясындагы өченче һәм җиденче абзацлар** үз көчләрен югалткан дип танырга;

**58) Уставның 91 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы

законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү формасында үзгәрешләр кертелгән очракта, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.»;

**59) Уставның 91 статьясындагы 4 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район Советы утырышында аларны карап тикшерү алдыннан Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары проекты буенча, Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү формасында үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш, әлеге Устав нигезендә гавами тыңлаулар үткәрелә.

**60) Уставның 94 статьясын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«94 статья. Район Уставының, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карарның үз көченә керү тәртибе

1. Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары кабул ителгәннән соң, Район Башлыгы тарафыннан Федераль законда билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрелә.

2. Район Уставы, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә. Район башлыгы теркәлгән Район Уставын, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан Район Уставы, Район Уставына үзгәрешләр кертү турында Район Советы карары хакында белешмәләрнең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертелүе турында «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган хәбәрнамә килгәннән соң җиде көн эчендә рәсми бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.

3. Район Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешүне үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр (район Уставын федераль законнарга туры китерү, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларның вәкаләтләрен, вәкаләтләре вакытын, сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан тыш), әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткән районның вәкиллекле органы вәкаләтләре вакыты чыккач, ә вәкиллекле орган «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль

законның 35 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты нигезендә формалашкан очракта - күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка имза куйган Район Башлыгы вәкаләтләре вакыты тәмамланганнан соң үз көченә керә.».

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин